**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021 елның «16» ноябреннән № 445

Халыкка күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтүгә
чик бәяне раслау турында

Халыкка түләүле хезмәт күрсәтү хокукына ия муниципаль учреждениеләрнең үтенечнамәләрен карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 17 статьясы һәм "Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 ел, № 273-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2021 елга Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә халыкка түләүле хезмәтләр күрсәтү хокукы булган муниципаль учреждениеләр тарафыннан халыкка күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтүгә иң чик бәяне кушымтага нигезендә расларга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 01.10.2021 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесенә әлеге карарны «Яңа Чишмә хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Халыкка күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә чик бәяне раслау

турында» 2019 елның 15 мартындагы 49 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фәсахов

Кушымта
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның «16» ноябрендәге 445 номерлы карарына

Закон нигезендә халыкка түләүле хезмәтләр күрсәтү хокукына ия булган муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан халыкка күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр өчен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә чик бәя

| № | Хезмәт исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе (сум) |
|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре | | | |
| 1 | Нәфис-эстетик цикл | 30 минут | 200,00 |
| 2 | Физкультура-сәламәтләндерү юнәлеше | 30 минут | 200,00 |
| 3 | Сәламәтләндерү һәм медицина хезмәтләре | 30 минут | 200,00 |
| 4 | Психолог белән дәресләр | 30 минут | 200,00 |
| 5 | Логопед белән дәресләр | 30 минут | 200,00 |
| 6 | Ял көне төркеме | 6 сәгать | 200,00 |